ГЛАВА СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с. Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар Постановление

“ 24” октября 2019 г. № 9

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка Урманчылыгы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Соколка Урманчылыгы авылы , Болын урамы , 25В нче йорт адресы буенча урнашкан Болын авылы административ йорты бинасында 2019 елның 7 нче ноябрь сәгать 09.00 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка Урманчылыгы авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка Урманчылыгы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Грахань авылында Совет урамында Бөек Ватан Сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү һәм кую (табличкалар, төзелеш материаллары сатып алу, территорияне төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);

- Соколка Урманчылыгы торак пунктындагы бистәләрендә юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка Урманчылыгы авыл җирлеге башкарма комитетына Соколка авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы: А.Г. Рахимзянов